**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

09.08.2013

№ 10-28/кс

Казан ш.

***Техник суга һәм ташландык суларны агызуга тарифлар билгеләү турында***

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу белән шөгыльләнүче оешмалар өчен техник суга һәм ташландык суларны агызуга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2013 елның 1 сентябреннән 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. Шушы карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмаларга ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.08.2013 № 10-28/кс карарына кушымта

## Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу белән шөгыльләнүче оешмалар өчен техник суга һәм ташландык суларны агызуга тарифлар

| Тәртип саны | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб. м. | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Менделеевск муниципаль районы | | |
| 1 | «Менделеевсказот» ҖЧҖ (тариф өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 12,72 | |
| | Саба муниципаль районы | | |
| 2 | «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ (тариф өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | | 14,97 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм